ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25 февраль, 2022 ел** **Олы Әшнәк авылы** **№ 4**

“2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең эчәргә яраклы суының сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү” инвестиция программасын эшләүгә техник биремне раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында” 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, “Су белән тәэмин итү һәм субүлү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге ”Су белән тәэмин итү һәм субүлү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестицион һәм җитештерү программалары турында” 641 номерлы карары нигезендә:

1. “2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең эчәргә яраклы суының сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү” инвестиция программасын эшләүгә техник биремне расларга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Хөснетдинова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары белән
расланды

**“2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең эчәргә яраклы суының сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү” инвестиция программасын эшләүгә техник бирем**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең эчәргә яраклы суының сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү” инвестиция программасы проектын эшләүгә техник бирем (алга таба тиңдәшле рәвештә текст буенча – Техник бирем, Инвестицион программа) түбәндәгеләр нигезендә эшләнде:

- РФ ның Җир кодексы;
- РФ ның Шәһәр төзелеше кодексы;
- “Су белән тәэмин итү һәм субүлү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон;
- РФ Региональ үсеш министрлыгының 2007 елның 10 октябрендәге “Коммуналь комплекс оешмаларының инвестицион программаларын эшләү буенча техник биремнәрне әзерләүгә методик тәкъдимнәрне раслау турында” 100 нче номерлы боерыгы;
- РФ Региональ үсеш министрлыгының 2013 елның 14 июнендәге “Җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне раслау турында” 502 нче номерлы боерыгы;
- СанПиН №2.1.3684-21 “Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак биналарга, җитештерү, җәмәгать биналарыннан файдалануга, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар оештыру һәм үткәрүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр”;
- СанПиН 1.2.3685-21 “Яшәү тирәлеге факторларының кеше өчен куркынычсызлыгын һәм (яки) зарарсызлыгын тәэмин итүгә гигиена нормативлары һәм таләпләре”.

2. Инвестицион программаны эшләү һәм тормышка ашыруның максатлары һәм бурычлары

2.1. Инвестицион программаны эшләү һәм тормышка ашыруның төп максаты:

эчәргә яраклы суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерүгә юнәлдерелгән чараларны башкару.

2.2. Инвестицион программаны эшләүнең бурычлары:

Эчәргә яраклы суның кирәкле күләмнәрен һәм сыйфатын тәэмин итү, эчәргә яраклы суның сыйфатына норматив таләпләрне үтәү.

Сыйфатлы суны чыганактан алып кулланучыга кадәр өзлексез бирүне тәэмин итү.

2.3. Инвестицион программаны эшләү һәм алга таба тормышка ашыру кулланучыларны су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын, сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны, аварияне һәм тузуны киметү, үткәрү сәләтен арттыруны һәм суның сыйфатын яхшыртуны тәэмин итәргә тиеш.

## 3. Максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр

3.1. Су белән тәэмин итү хезмәте күрсәтүнең максатчан индикаторлары һәм сыйфат күрсәткечләре.

Абонентның эксплуатация җаваплылыгы чигендә эчәргә яраклы суның сыйфатын түбәндәге күрсәткечләр буенча дәүләт стандартына туры килә торган дәрәҗәгә җиткерү:

- тимер буенча 0,3 мг/куб. дм дан артмаслык;
- марганец буенча 0,1 мг/ куб.дм дан артмаслык;
- тоныклык буенча 1,5 мг/ куб.дм дан артмаслык;
- катылык буенча 7 мг-экв/л дан артмаслык;
- микробиологик күрсәткечләр буенча канәгатьләнмәслек пробалар процентын киметү.

## 4. Инвестицион программаны эшләү вакыты

4.1. Инвестицион программа проектын эшләү вакыты – техник бирем расланганнан соң 6 ай эчендә.

## 5. Инвестицион программаны эшләүче

5.1. Инвестициин программаны эшләүче – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге.

## 6. Инвестицион программага таләпләр

6.1. Инвестицион программаны эшләгәндә зарур:

- билгеләнгән таләпләр нигезендә эчәргә яраклы суның тиешле сыйфат дәрәҗәсен тәэмин итәргә мөмкинлек бирми торган төп проблемаларны чагылдырып, су белән тәэмин итү системаларының хәзерге торышына (халәтенә) анализ ясарга.
- эчәргә яраклы суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү буенча чаралар планын эшләргә һәм аны Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсе районнарындагы кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт Идарәсенең территориаль бүлеге белән килештерергә.

Эчәргә яраклы суның сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү буенча чаралар планы инвестицион программа составына кертелә.

- инвестицион программа чараларын тормышка ашыруга финанс ихтыяҗлары күләмен билгеләү:

чараларны тормышка ашыруга финанс ихтыяҗлары күләмен һәр чараны тормышка ашыруга финанс ихтыяҗларын кушу юлы белән билгеләргә;

инвестицион программа чараларын тормышка ашыруга финанс ихтыяҗларын төзелеш һәм реконструкция бәясенең, гамәлдәге норматив базаның эреләндерелгән күрсәткечләре нигезендә билгеләргә (дәүләт элемент нормалары, федераль берәмлек расценкалары).

6.2. Инвестицион программаны финанслау чыганаклары булырга мөмкин:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең үз акчалары;

- федераль, региональ, муниципаль максатчан программаларны тормышка ашыру барышында тәгаенләнә торган финанс чаралары.

6.3. Инвестицион программада кирәк:

финанс ихтыяҗларын билгеле бер финанслау чыганаклары буенча үткәрү, шул исәптән инвестицион программаны тормышка ашыру еллары һәм этаплары буенча бүленеш белән;

тоташтыруга тарифларга һәм тарифларга өстәмәләр исәп-хисапларын үтәргә;

инвестицион  шартнамә проектын әзерләргә;

эшләнә торган инвестицион программаның төрле программалар кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестицион программа чараларын икеләтә исәпкә алу мөмкинлеген булдырмас өчен  җитештерү программасы белән ярашуын тәэмин итәргә.

6.4. Инвестицион программа буенча эшләрне координацияләүне (килештерүне) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге башкара;

6.5. Инвестиция программасы тасвирлау һәм таблица өлешләреннән торырга тиеш;

6.6. Инвестицион программа үз эченә алырга тиеш:

а) инвестицион программаның  түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган паспорты:

инвестиция программасы эшләнә торган оешманың  аталышы (исеме), аның урнашу урыны;

инвестицион программаны раслаган вәкаләтле орган аталышы (исеме), аның урнашу урыны;

инвестиция программасын килештерүче авыл җирлегенең җирле үзидарә органы аталышы (исеме), аның урнашу урыны;

федераль дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы чаралар планын килештергән федераль башкарма хакимият органының территориаль органы аталышы (исеме);

б) оешма эшчәнлегенең максатчан Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан инвестиция программасын гамәлгә ашыру срогы дәвамында һәр елга аерым билгеләнгән күрсәткечләре, шул исәптән энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру күрсәткечләре;

в) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яки) субүлү системалары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләүгә проект документларын әзерләү буенча чаралар исемлеге, инвестицион программа чараларының кыскача тасвирламасы, шул исәптән аларның кирәклеген нигезләү, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яки) субүлү системаларының төзелә, реконструкцияләнә һәм модернизацияләнә торган объектларының тасвирламасы (урнашу урыны), тасвирлама мондый объектларны бертөрле идентификацияләүне тәэмин итә, мондый объектларның төп техник сыйфатламалары чараны гамәлгә ашырганга кадәр һәм аннан соң. Инвестицион программа чаралары су белән тәэмин итү өлкәсендә тормышка ашырыла торган чараларга һәм субүлү өлкәсендә тормышка ашырыла торган чараларга бүленә;

г) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яки) субүлү системаларын һәм аларның аерым объектларын техноген, табигый характердагы һәм террорчылык актларыннан яклау (саклау), гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне булдырмау, хәвеф-хәтәрләрне киметү һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен йомшарту буенча чаралар;

д) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яки) субүлү системалары объектларын файдалануга тапшыру графигын да кертеп, инвестицион программа чараларын гамәлгә ашыру графигы;

е) инвестицион программаны тормышка ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме турында мәгълүматлар, инвестицион программаның аерым чаралары буенча бүлеп инвестиция программасын финанслау чыганакларын күрсәтеп. Оешма тарафыннан коммуналь инфраструктура системасы булган концессион килешү төзелгән очракта, инвестицион программаны финанслау чыганаклары концессион килешү шартлары нигезендә билгеләнә;

ж) оешма эшчәнлегенең максатчан күрсәткечләрен үзгәртү динамикасын һәм аның гамәлдә булу вакыты чорында инвестиция программасын гамәлгә ашыру чыгымнарын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган акчаларны инвестицияләүнең нәтиҗәлелеген исәпләү;

з) инвестицион программаны тормышка ашыру чорына су белән тәэмин итү һәм (яки) субүлү өлкәсендә тарифларны алдан исәпләү;

и) энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар планы һәм программасы.

6.7. Инвестицион программа проектын, кирәкле финанс ихтыяҗларын, тарифларга өстәмәләрне һәм тоташтыру өчен тарифларны Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсе районнарында кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт Идарәсенең территориаль бүлегенә килештерү өчен җибәрергә кирәк.

6.8. Финанс ихтыяҗлары инвестицион программа чараларын үткәрүгә бәйле барлык чыгымнар комплексын үз эченә ала:

- проект-эзләнү эшләре;
- материаллар һәм җиһазлар сатып алу;
- төзелеш-монтажлау эшләре;
- техник-икътисадый сыйфатламаларны яхшырту нияте белән җиһазларны алыштыру буенча эшләр;

- көйләп җибәрү эшләре;

- объектларны теркәү уздыру;

- төп средстволар бәясенә керми торган чыгымнар (төзелеш вакытына җирне арендалау һ.б.).

6.9. Инвестиция программасы һәр чара буенча финанслау чыганакларын үз эченә алырга тиеш.

6.10. Чараларның бәясе чараларны тормышка ашыру елына тиңдәшле бәяләрдә китерелергә тиеш. Инвестицион программа чараларын тормышка ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме җитештерү булмаган объектлар һәм инженерлык инфраструктурасы өчен эреләндерелгән смета нормативларын исәпкә алып билгеләнә.

## 7. Техник биремгә үзгәрешләр кертү тәртибе

7.1. Расланган техник биремне яңадан карау (үзгәрешләр кертү) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге инициативасы белән гамәлгә ашырыла.

7.2. Расланган техник биремне яңадан карау (үзгәрешләр кертү) өчен нигез булып тора:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш программаларына һәм техник бирем шартларын үзгәртүгә йогынты ясый торган башка программалар кабул итү яисә үзгәрешләр кертү;

коммуналь инфраструктурасы системаларына тоташтырыла торган төзелүче объектларның техник биремен раслаганда өстәмәләр кертү һәм (яки) кабул ителгәннәрне, шулай ук инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин ителгән җир кишәрлекләре исемлеген дә төшереп калдыру.

7.3. Техник биремне яңадан карау (үзгәрешләр кертү) елына бер тапкырдан да ешрак башкарылырга мөмкин түгел.